# КАРАР

## Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль Федоровка авыл җирлегенең Алекина Поляна торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**06 декабрь 2019 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2019 елның 6 декабрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләренә таянып, түбәндәге мәсьәлә буенча беркетмә төзелде: «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Федоровка авыл җирлегенең Алекина Поляна торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, I төркем инвалидлар, ирегеннән мәхрәм ителү урыннарында булучы затлар дан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Алекина Поляна авылы эчендәге юлларны ремонтлаутөзекләндерү;

-Алекина Поляна авылы зираты территориясен койма белән әйләндереп алу?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булучы җыенда катнашучылар исемлегенә 108 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны - 57 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 45 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 12 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Федоровка авыл җирлегенең Алекина Поляна торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныйрга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип таныйрга.

2. Әлеге мәсьәлә буенча: «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Федоровка авыл җирлегенең Алекина Поляна торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, I төркем инвалидлар, ирегеннән мәхрәм ителү урыннарында булучы затлар дан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Алекина Поляна авылы эчендәге юлларны ремонтлаутөзекләндерү;

-Алекина Поляна авылы зираты территориясен койма белән әйләндереп алу?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

карар кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълъмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

**Халык җыенында рәислек итүче** **М.Ю. Никонорова**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлеге башлыгы** **М.Ю. Никонорова**